# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ИСКЕ УЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

№3 07 ноябрь 2023 ел

«"Аксубай муниципаль районы Иске Узи авыл җирлегенең
Яңа Баланда авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Аксубай муниципаль районы «Иске Узи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясына ярашлы

Карар итәм:

1. 2023 елның 17 ноябрендә ТР, Аксубай районы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Узи авыл җирлегенең Яңа Баланда авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены Яңа Баланда авылы, Киров урамы адресы буенча 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Аксубай муниципаль районы Иске Узи авыл җирлегенең Яңа Баланда авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә,( 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан , шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларны гайлә әгъзаларыннан тыш) алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (юл япмасын төзү (туфракны күтәрү, урамнарны вак таш белән күмү, вак таш сатып алу).

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә урамнарны кышкы тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу);

2. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту

ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратта агачлар һәм үсентеләр кисү килешүе буенча хезмәтләр өчен түләү).

РИЗА КАРШЫ

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күпләп җыела торган урыннарына, стендларга һәм белдерү такталарына элгән килеш игълан итәргә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Аксубай муниципаль районы
Иске Узи авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Айдова